ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2023 елның 13 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 74**

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендә һәм салым салынырга тиеш, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән һәм шулай ук «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы»Коммерциячел булмаган партнерлыгының 2023 елның 31 гыйнварындагы 18 номерлы хатына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендәге һәм гаиләнең һәр әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясенең иң чик күрсәткече - 316 980 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече - 7714 сум.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов